| | |
|---|---|
| РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО<br>КОМИТЕТА БУГУЛЬМИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.09.2016 г.Бугульма №1186

**Дәүләт мөлкәтенә кертелгән архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында:

1. Дәүләт мөлкәтенә кертелгән архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең «Яңа редакциядә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 19 июнендәге 672 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүмати технологияләр бүлегенә әлеге карар кабул ителгәннән соң, 3 эш көне эчендә аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә – Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасарына йөкләргә.

Бөгелмә муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе
вазифаларын башкаручы В.В. Гарәфетдинов